**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Чубар-Абдул авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Чубар-Абдул авылы №54 «18» апрель 2022 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл 2020 елның 26 февралендәге 171 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Чубар-Абдул авыл җирлегенең бюджет корылышы һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Чубар-Абдул авыл җирлегенең бюджет корылышы һәм бюджет процессы турында нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында (24.04.2020 №175, 15.06.2020 №181, 16.12.2020 №26, 27.10.2021 №39 карарлар редакциясендә)

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, 2021 елның 29 11 декабрендәге 384-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм 2022 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында» Федераль закон нигезендә,

**Чубар-Абдул авыл җирлеге карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлегенең 2020 елның 26 февралендәге 171 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Чубар-Абдул авыл җирлегенең бюджет корылышы һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Чубар-Абдул авыл җирлегенең бюджет корылышы һәм бюджет процессы турында нигезләмәгә (24.04.2020 №175, 15.06.2020 №181, 16.12.2020 №26, 27.10.2021 №39 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 6 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле яңа унберенче абзац өстәргә:

«гражданнарның бюджет процессында катнашуы;»;

б) унберенче - ундүртенче абзацларны уникенче - унбишенче абзацлар дип санарга.

1.2. 20 статьяның 2 пунктында «җирле бюджет кытлыгы» сүзләреннән соң «инфраструктура проектларын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүгә җәлеп ителгән бюджет кредитының тиешле ел ахырына файдаланылмаган калдыгы күләменнән тыш»сүзләрен өстәргә.

1.3. 55 статьяның унбишенче абзацын үз көчен югалткан дип танырга.

1.4. 58 статьяның 3 пунктында «әгәр Россия Федерациясе Бюджет кодексында башкасы каралмаган булса» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Азнакай районы авыл җирлегенең бюджет, финанс, салымнар һәм икътисад мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис: Н.Ә.Фәтхетдинов